**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ — КАРАР

30.10.2020 ел — №19

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау хакында, яңа редакциядә» 21.10.2019 елдагы № 165 карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 31.07.2020 елдагы № 263-ФЗ Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының 21.10.2019 елдагы № 165 (2020 елның 14 апрелендәге № 199, 04.08.2020 елдагы № 224 үзгәрешләр белән) "Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмә яңа редакциядә» түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 9 статьяның 2 пункты үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. 35 статьяның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тиешле бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм бюджет турында закон проектын (карарларны) закон чыгару (вәкиллекле) органына керткәннән соң кабул ителгән район Советының норматив-хокукый актлары агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка үзгәрешләр керткәндә чираттагы финанс елында исәпкә алына.»;

2. Әлеге карарны ТР хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Әтнә муниципаль районы башлыгы -
Әтнә район Советы рәисе вазыйфаларын
башкаручы — Ф.М. Нуриев